**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЯҢА ЧИШМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яна Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

29 нчы июнь 2022 ел № 20-74

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 мартында 53-175 нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законы, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 нче мартында 53-175 нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (18.02.2021 №6-21, 06.07.2021 №11-37 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
- 2.4 статьяның 2 пунктының 13 абзацында «2.4 статьясындагы 1 пунктында» сүзләрен «2.4 статьясындагы 2 пунктының 3 абзацында» сүзләренә алмаштырырга;
- 2.4 статьясындагы 3 пунктының 2 абзацында «2022 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының социаль сәясәт комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге башлыгы В.М.Козлов